**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреленнән

№ 9-53

2025 елда «2023-2030 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру һәм 2026 елга бурычлар турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы Г. И. Шәрәпова 2025 елда «2023-2030 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру һәм 2026 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы Г. И. Шәрәпова 2025 елда «2023-2030 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру һәм 2026 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә:

- балалар бакчаларында федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә торган, шул исәптән сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дә, шартлар тудыру эшен дәвам итәргә;

- районда гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (алга таба - ГДББС) таләпләре нигезендә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең сыйфатын мониторинглау системасын булдырырга;

- белем бирүнең сыйфаты һәм мәгариф оешмалары эшенең нәтиҗәләре турында мәгълүматның мөмкин кадәр ачык һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итәргә;

- районның мәгариф учреждениеләре укучылары һәм тәрбияләнүчеләренең республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашуын тәэмин итәргә;

- белем бирү сыйфатын бәяләүдә тышкы дәүләт- иҗтимагый ролен көчәйтү һәм эчке һәм тышкы бәяләүнең үзара оптималь хезмәттәшлегенә ирешергә;

-кулланучыларның белем бирү хезмәтләрен сайлый алу, белем бирүнең эчтәлегенә һәм технологияләренә төзәтмәләр кертүне тәэмин итә торган хосусый белем казанышлары турында мәгълүмат җыю һәм анализлау системасын булдырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими комиссиягә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы — Е.А.Тарнавский